ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 3 09.11. 2020 ел.

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге башлыгы

К А Р А Р  И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Подгорный бистәсе, Үзәк урам, 22А йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасы янында 2020 елның 21 ноябренә 10.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Подгорный бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Подгорный торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъълык яшенә җиткән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә 400(дүрт йөз) сум күләмендә түләргә һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Подгорный торак пунктында зират юлын норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, төзелеш материаллары сатып алу, вак ком-таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктына керү юлын норматив хәлгә китерү (төзелеш, рекон - струкция, асфальтлау, ремонт, вак таш җәю, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Подгорный торак пунктының Нагорная урамында яңгыр сулары агучы канализация-ләрне ремонтлау ( материаллар сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча -Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

"Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы Ф.В.Әхмәтов